8 апрельдә беренче тапкыр Мордовия Республикасы Моселманнары диния идарәсе оештырган Коръән укучыларнын тобәкара конкурсы vтте. Чара Саранскта, Республика мәдәният сараенда узган. РДКнын зур залы тулысынча кунаклар белән тулган. Чарада барлыгы 1000нән артык кеше катнашкан.




Конкурста катнашу очен 10 тобәктән: Саратов, Пенза, Рязань, Ярославль олкәләреннән, Татарстан Республикасыннан, шулай ук Россиянен башка тобәкләреннән кунаклар катнашкан. 21 катнашучы 3 джуза, 5 джуза һәм 10 джуза номинацияләрендә Изге Коръән текстын яттан белvләрен кvрсәткәннәр.
Конкурс безнен тормышыбызда Коръәннен кыйммәте турында кечкенә фильм белән ачылган, аннары Саранск шәһәренен «Ааль-Мансур» Үзәк Жәмигъ мәчете имамы Ибраһим Асаинов изге Китапнын аятьләрен укыган. Конкурсны vз чыгышы белән Мордовия Республикасы Моселманнары диния идарәсе мофтие Раиль хазрәт Асаинов ачкан. Ул барлык кунакларга чакыруга жавап биргәннәре һәм конкурста катнашканнары очен рәхмәтен белдергән, бигрәк тә мофтиләргә, башка республикалардан һәм олкәләрдән килгән дин әһелләренә. Алар, изге Рамазан ае коннәрендә, тыгыз график булуга карамастан, чарага килергә вакыт тапканнар.
Мофти Раиль хазрәт Асаинов Мордовия Республикасы Башлыгы Артём Алексеевич Здуновка һәм анын командасына әлеге чараны vткәрvдә ярдәм иткәне очен зур рәхмәтен белдергән.
Чараны оештыручылар һәм кунаклар адресына морәжәгатьне Мордовия Рес-публикасы Башлыгы һәм Мордовия Республикасы Хокvмәте Администрациясе исеменнән МР Мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министры урынбасары Альберт Борис улы Сявкаев укыган. Ә Россия моселманнарынын рухи лидеры, мофти шәйх Равиль Гайнетдин исеменнән морәжәгатьне РФ моселманнары Диния нәзарәте рәисенен Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Монир хазрәт Беюсов ишеттергән. Конкурста катнашучыларны һәм кунакларны Саратов олкәсе мофтие Мукаддас хазрәт Бибарсов, Пенза олкәсе мофтие Ислям хазрәт Дашкин, Рязань олкәсе мофтие Рәшид хазрәт Бултачеев, Коръән хафизларын әзерләv vзәге директоры Ростәм хазрәт Фәизов

сәламләгән. Ярославль олкәсе мофтие дә сәламләгән, әмма ул сонгы мизгелдә конкурска килә алмаса да, ин яхшы теләкләрен юллаган.
Конкурс жюри әгъзалары Коръәннен дvрт хафизы булды. Судьялар коллегиясенә жюри рәисе - Пенза олкәсе моселманнары Диния идарәсе рәисе, мофти Ислям хазрәт Дашкин керә. Жюри әгъзалары: Казан шәһәре Коръән хафизларын әзерләv vзәге житәкчесе Ростәм Рәшид улы Фаизов; Коръән хафизы Харис Абдулхак улы Аберхаев; Коръән хафизы, Россия ислам институты студенты Әхмәт Камиль улы Бадретдинов.
Традиция буенча жюри конкурс-та катнашучыларнын Изге Китапны укуларынын дореслеген һәм матурлыгын бәяләде. Нәтижәдә урын тvбәндәгечә бvленгән.
3 джуза номинациясендә:
1 урын - Солтов Али (Ивановск олкәсе),
2 урын - Сюньков Абдуррахман (Ульяновск олкәсе),
3 урын - Сәйфетдинов Мохәм-мәтшәриф (Рязань олкәсе).
5 джуз номинациясендә:
1 урын - Йосыпов Ибраһим (Мордовия Республикасы),
2 урын - Назриев Әхмәджон (Яро-славль олкәсе),
3 урын - Жумаев Холид (Ульяновск олкәсе).
10 джуз номинациясендә:
1 урын - Коленков Халид (Пенза олкәсе),
2 урын - Мәрдаев Эльбек (Рязань олкәсе),
3 урын - Гайфуллин Золкарнай (Татарстан Республикасы).
Барлык катнашучылар истәлекле сертификатлар һәм бvләкләр белән бvләкләнгәннәр. Топ 10 джуз номинациясендә жинvче 50 000 сум кvләмендә акчалата бvләктә ала. Шулай ук Моселманнарнын диния идарәсеннән Коръәнне ойрәтv буенча кvпьеллык хезмәте очен мофти урынбасары, имам-мохтәсиб Рәшит хазрәт Абдрашитов Рәхмәт хаты (Благодарность) белән бvләкләнә.
Коръән укучылар конкурсы кысаларында тамашачылар арасында кечкенә хажга (Умра) ике юллама уйнатылган.
Конкурс ахырында 1500гә кеше - катнашучылар һәм кунаклар хәйрия ифтарында катнаша.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**